РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА
ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГӘЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Садовая, дом 17,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» октябрь 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Гәйтән торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 29 октябрендә 15 сәгать 00 минутка Үзәк урам 13нче йорт адресы буенча клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Гайтән авылында Спортивная урамы, 1-75нче йортларда, Рабочая урамы №1-24, Озерная урамы, №1-13нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 30 октябрендә 13 сәгать 00 минутка Үзәк урам 13нче йорт адресы буенча клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Гайтән авылында Полевая урамында №1-28, Садовая урамы №1-30нче, Заречная урамы №1-7нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2025 елның 31 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Үзәк урамы 13нче йорт адресы буенча клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Гайтән авылында Центральная урамында №1-22, Молодежная урамы №1-39нчы, Мира урамы №1-6нчы, Восточная урамы 2-8нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Гайтанкино авылында яшәүчеләр исемлеген аеруны сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты белән тәэмин ителә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2024 елда Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Гайтән авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

2) урам утларын карау.
3) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.
4) торак пункт территориясен төзекләндерү.
5) традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева